**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 6 июль | № 496

г. Казань

«Зеленодольск балалар йорты» ятим балалар һәм əти-əни каравыннан мəхрүм калган балалар өчен дәүләт бюджет мәгариф учреждениесен бетерү турында

Россия Федерациясе Президентының «Ятим балаларны һәм əти-əни каравыннан мəхрүм калган балаларны яклау тармагында дәүләт сәясәтен тормышка ашыруның кайбер чаралары турында» 2012 ел, 28 декабрь, 1688 нче Указын үтәү өчен, шулай ук ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруны үстерү буенча дәүләт сәясәтен камилләштерү һәм алга таба чаралар комплексын гамәлгә ашыру, интернаты булган мәгариф оешмалары челтәрен карап тотуга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү һәм мәгариф оешмалары мөлкәтеннән нәтиҗәле файдалану максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкарган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 422520, Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Северный урамы, 9 йорт адресы буенча урнашкан «Зеленодольск балалар йорты» ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен дәүләт бюджет мәгариф учреждениесен (алга таба – Балалар йорты) бетерү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

14 көн вакыт эчендә:

Балалар йортын бетерү буенча комиссия составын расларга;

Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә Балалар йортын бетерү тәртибен һәм вакытын билгеләргә;

Балалар йортын бетерү турында карар кабул иткәннән соң 3 көн эчендә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен теркәүче органга Балалар йорты бетерү процессында булу хакында белешмәләр тапшырырга;

бу карарны кабул иткән мизгелдән соң, законнар таләпләрен саклап, Балалар йортында тәрбияләнүчеләрне «Сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен Казанның 11 нче мәктәп-интернаты» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә (алга таба – Казанның 11 нче мәктәп-интернаты) күчерүне тәэмин итәргә;

Балалар йортын бетерү буенча законнарда каралган чараларның бетерү комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә, шулай ук бетерү нәтиҗәсендә эштән чыгарылучы хезмәткәрләргә Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына «Зеленодольск механика көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенә (алга таба – Зеленодольск механика көллияте) беркетү өчен Балалар йорты мөлкәте исемлеген тапшырырга.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

30 көн эчендә Зеленодольск механика көллиятенә оператив идарә итү хокукында Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан бирелгән Балалар йорты мөлкәте исемлеге нигезендә элек оператив идарә итү хокукында Балалар йортына беркетелгән аеруча кыйммәтле күчемле милекне беркетүне тәэмин итәргә;

120 көн эчендә элек даими файдалану (вакыты чикләнмәгән) хокукында Балалар йортына беркетелгән булган, аларда күчемсез милек объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен Зеленодольск механика көллиятенә тапшыруны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына билгеләнгән тәртиптә тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына тиешле үзгәрешләрне кертү хакында тәкъдимнәр бирергә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисади һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә барлык үзгәртеп төзү чараларын үткәргәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карарына, аны әлеге карарның 2 пунктындагы сигезенче абзацка яраштыру өлешендә, үзгәрешләр кертү хакында карар проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков